# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

25.11.2020 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 25.10.2019 елның 27 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына таянып 2020 елның 25 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2021 нче елда Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Шәмәрдән торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Шәмәрдән торак пунктында контейнер мәйданчыклары тезү;
- Шәмәрдән торак пунктында яңа зират территориясен койма белән әйләндереп алу эшләрен башкару.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 4774 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 2484 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 2453 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 31 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында халык җыенын үткән дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип таныргa.

1. «2021 нче елда Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Шәмәрдән торак пунктында Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә” һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

- Шәмәрдән торак пунктында контейнер мәйданчыклары төзү;

- Шәмәрдән торак пунктында яңа зират территориясен койма белән әйләндереп алу эшләрен башкару.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shemordan адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Шәмәрдән авыл
җирлеге башлыгы

А.Н.Гәрәев